2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү ДТМ-экспертиза материалларын кушымталар белән Орган сайтына урнаштырган мизгелдән 15 эш көненә туктатыла.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) регламентның 2.5 пунктында санап үтелгән документларның тулы булмаган комплектын тапшыру, аларда тулы булмаган яки дөрес булмаган белешмәләр булу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен нигез булып торган бер яки берничә документның гамәлдә булуы бетү яисә тукталып тору;

3) документлар моңа вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан тапшырылган һәм имзаланган;

4) мәдәни мирас объектына карата мөрәҗәгать итүчедә вәкаләтләр булмау, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең мәдәни мирас объекты хокукына ия булу яки мәдәни мирас объекты кулланучысы мәнфәгатьләрендә эш итү хокукын раслый торган документлар булмау;

5) мәдәни мирас объектларын саклау органы экспертизасының нәтиҗәләре белән килешмәү, ул бу хакта язмача, ризасызлыкның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, заказ бирүчегә хәбәр итә. Ризасызлык сәбәпләренә түбәндәгеләр карый:

а) ДТМ-экспертиза бәяләмәсен рәсмиләштергән көннән 3 ел вакыт узу;

б) ДТМ-экспертиза бәяләмәсендә бирелгән документлар буенча тискәре нәтиҗәләр тупланган;

в) экспертиза бәяләмәсен имзалаган экспертка карата түбәндәгеләр ачыклану:

- заказ бирүче (аның вазыйфаи заты яки хезмәткәре) белән туганлык элемтәләре булу (балалары, ир белән хатын, ата-аналар, бертуган һәм атасы яисә анасы башка булган абыйлары һәм апалары (туганнан- туган энеләре һәм сеңелләре), икетуган абыйлары һәм апалары, заказ бирүченең (аның вазыйфаи заты яки хезмәткәре) ата-анасының бертуган һәм атасы яисә анасы башка булган абыйлары һәм апалары;

- заказ бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтләре булу;

- заказ бирүче (аның вазыйфаи заты яки хезмәткәре) каршында бурыч яки башка мөлкәт йөкләмәләре булу, шулай ук заказ бирүченең (аның вазыйфаи затының яки хезмәткәренең) эксперт каршында бурыч яки башка мөлкәт йөкләмәләре булуы;

- заказ бирүченең кыйммәтле кәгазьләренә, акцияләренә (катнашу өлешләренә, устав (җыелма) капиталларында пайларга) ия булу;

- акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, мөлкәти характердагы хезмәтләр күрсәтү яки мөлкәти хокуклар рәвешендә үз-үзеңә яки өченче затлар өчен табыш алу максаты белән тикшеренүләр нәтиҗәсе яисә экспертиза бәяләмәсеннән килеп чыга торган карар белән кызыксыну;

6) ДТМ-экспертиза үткәрүнең билгеләнгән тәртибен бозу;

7) экспертиза үткәрү өчен дөрес булмаган белешмәләр булган документлар тәкъдим итү:

а) тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгать, фән һәм техника, эстетика, этнология һәм антропология, социаль культура күзлегеннән караганда объектның кыйммәтләре турында мәгълүматны үз эченә алган материаллар;

б) экспертиза үткәрү өчен шартнамә төзелгән вакытка объектның график сурәтләреннән фото;

в) мәдәни мирас объектларын саклау зоналары проектлары;

г) мәдәни мирас объекты паспортының күчермәләре;

д) мәдәни мирас объекты милекчесенең яисә күрсәтелгән объект кулланучысының (сак-аренда шартнамәсе, сак шартнамәсе) сак йөкләмәләре күчермәләре;

е) мәдәни мирас объектын реестрга кертү турында дәүләт хакимияте органы карары күчермәләре;

ж) мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен һәм күрсәтелгән чикләрдә җир кишәрлекләренең хокукый режимын раслау турында дәүләт хакимияте органы карарының күчермәләре;

з) тарихи җирлек чикләрендә урнашкан күчемсез милек объектлары һәм мәдәни мирас объектларын саклау зоналары өчен тарихи-мәдәни терәк планы яки аның фрагменты;

и) тарихи-мәдәни терәк планы яисә аның фрагменты яисә тарихи-мәдәни тыюлыкның тәкъдим ителә торган чиге нигезләнә торган башка документлар һәм материаллар;

к) мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга проект документлары;

л) югалган мәдәни мирас объектын торгызуны нигезләүче документлар;

м) мәдәни мирас объекты һәм (яки) җир кишәрлекләренә хокукны раслый торган (билгели торган) документлар күчермәләре;

н) мәдәни мирас объектына һәм (яки) аның территориясе чикләрендәге җир кишәрлекләренә теркәлгән хокуклар турында белешмәләрне үз эченә алган Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр;

о) мәдәни мирас объекты һәм аның территориясе чикләрендә күчемсез милек дәүләт кадастрына кертелгән җир кишәрлекләре турында белешмәләр (тиешле кадастр өземтәләре, паспортлар, территория планнары һәм белешмәләр күчермәләре);

п) мәдәни мирас объектына техник паспортның һәм (яки) Дәүләт техник исәбен һәм (яки) капиталь төзелеш объектларын техник инвентаризацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларга бирелә торган биналарның күләмнәрен күрсәтеп һәм аңлатмасын (экспликациясен) китереп, аның катлар планының күчермәләре;

р) мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә җирләрдән файдалану режимнарын һәм шәһәр төзелеше регламентларын раслау турында дәүләт хакимияте органы актының (актларының) күчермәләре;

с) мәдәни мирас объектын саклау зоналары һәм Күчемсез милек дәүләт кадастрына кертелгән күрсәтелгән зоналар чикләрендәге күчемсез милек объектлары турында белешмәләр (тиешле кадастр өземтәләренең, паспортларның, территория планнарының һәм белешмәләрнең күчермәләре);

т) тиешле территорияләрнең кадастр планнарында яки кадастр карталарында җир кишәрлекләренең урнашу схемалары;

у) җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләр башкару күздә тотылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы күчермәләре;

ф) күчемсез милек дәүләт кадастрына кертелгән югалган мәдәни мирас объекты гамәлен туктату турында, шулай ук алар нәтиҗәсендә кадастр исәбенә алу органына мәдәни мирас объекты булган күчемсез милек объектын исәптән төшерү турында гариза тапшыру өчен документлар әзерләү тәэмин ителә торган кадастр эшләрен башкарганда төзелгән тикшерү акты белешмәләре;

8) мәдәни мирас объектларын саклау органының ДТМ-экспертиза бәяләмәсе белән килешмәве;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле Россия Федерациясе законнарын бозу турында нәтиҗәләрне тупланган законлы көченә кергән суд акты булу;

10) әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, ведомствоара гарызнамәгә дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына буйсынган оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны раслый торган җавабы керү;

11) әгәр аңа карата гариза кергән бина федераль, республика (региональ) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты, шулай ук ачыкланган мәдәни мирас объекты булып саналса.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү вакытлары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүмат

теркәлү номеры ____________________________________________________,
биреңү датасы _______________________________________________________________.
Мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрне башкаруга бирелгән йөкләмә турында белешмәләр:
теркәлү номеры ____________________________________________________,
бирелү датасы _______________________________________________________________,
җаваплы вәкил _____________________________________________.
(Ф.И.А.)
Элемтә телефоны (шәһәр кодын кертеп):
________________________________________________________________________________.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен түбәндәгечә бирүегезне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинетка;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә;

☐ Органга

_________________ (дата)    _____________________ (имза) (________________________ (Ф.И.А.))

